РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
МОКРОСАВАЛЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МӨКЕРЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

18 октябрь 2022ел № 56-2

Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен Татарстан Республикасы «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында, аның предметы җирлек территориясен төзекләндерү һәм әлеге мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу кагыйдәләрен үтәүдән гыйбәрәт

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 15 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Буа муниципаль районының Мөкерле авыл җирлеге Уставы нигезендә, Буа муниципаль районының Мөкерле авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен Татарстан Республикасы «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшырырга, аның предметы җирлек территориясен төзекләндерү һәм әлеге мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу кагыйдәләрен үтәүдән гыйбарәт.
2. Әлеге карарны Буа муниципаль районы Советына карау өчен җибәрергә..
3. Вәкаләтләрнең бер өлешен башкаруны тапшыру Мөкерле авыл җирлеге бюджетыннан ел саен Татарстан Республикасының «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән гамәлгә ашырыла.
4. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

ТР Буа муниципаль районының
Мөкерле авыл җирлеге башлыгы С.Н. Тюплина